| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кадыбашского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кадыбаш авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2021 Кадыбаш № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Касай авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башлыгы к а р а р и т т е:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Касай торак пунктында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2021 елның 30 ноябрендә 10 сәг 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорау итеп расларга: «2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кадыбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Касай торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм irектән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу һәм ремонтлау, Касай авылында су үткәрү челтәрен төзекләндерү;

2. Касай авылын кардан чистарту (хезмәт шартнамәсе буенча тракторчы өчен түләү);

3. Касай авылы зиратын карап тоту (төзелеш материаллары сатып алу һәм коймаларны яңарту)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Касай ав., Центральная, 19Б йорт адресы буенча авыл клубында үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кадыбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Х.Л.Закиров